# “Казаным – башкалам” темасына үткәрелгән ачык дәреснең планы.

## ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ

**11 нче сыйныф, рус төркеме**

**Укытучы: Фәтхетдинова Рузилә Ринат кызы**

**Максат:** Казан турында булган белемнәрне ныгыту, тулыландыру, язма һәм бәйләнешле сөйләм телен үстерү, сочинение язарга әзерләү, туган илгә мәхәббәт хисләре тәрбияләү.

**Җиһазлау:** Казанның тарихи һәм истәлекле урыннары һәм югары уку йортларыннан күренешләр, интерактив тактага язылган сораулар, Казан шәһәренә багышланган видеоязма, “Казаным җыры”,презентация.

**Дәрес тибы**: белемнәрне камилләштерү.

## ДӘРЕС БАРЫШЫ:

1. Оештыру. Укучылар белән исәнләшү, дәреснең темасын,максатын әйтү.
2. Өйгә эшне тикшерү:

I. **Әңгәмә:**
   - Татарстанның табигате,
   - Татарстан дәүләтенең символикасы,
   - Эре шәһәрләр.

Татарстанның иң зур шәһәрләреннән берсе – Казан шәһәре.

II. 5 нче күнегүне тикшерү. /149 нчы бит/

**Русчадан татарчага тәрҗемә итәргә иде.**

Казань – древнейший город. Город расположен на левом берегу Волги. В различных учебных заведениях Казани готовят учителей, экономистов, юристов, менеджеров и других специалистов.

И сейчас Казань – один из крупных центров науки и культуры. В Казани много мест отдыха. Это – дворцы культуры, Дворец спорта, музеи и театры, выставки, филармония и цирк.

Казан турында сөйләшүне дәвам итәбез**. Интерактив тактадагы сорауларны укыйбыз, тәрҗемә итәбез**.

Видеоязманы караганда шул сорауларга җавап эзләгез.

- Казан нинди елгалар буенда урнашкан?
- Казан исеме каян барлыкка килгән?
  - Риваятьләр ни сөйли?
  - Бөек шәхес фикере буенча... / Ш.Мәрҗани фикере /
- Тарихи һәм истәлекле урыннар.
- Казанга ничәнче елда 1000 ел булды?
- Казанда булган һәм яшәгән күренекле кешеләр.
- Казанда ничә югары уку йорты бар?

**4.Компьютерда Казан шәһәре турында видеоязма карау һәм тактадагы сорауларга җавап бирү.**
**5.Дәреслек белән эш.** (147б)
Казанда уку йортлары.
Казан – мәдәни үзәк.
Тексттан табу, тәрҗемә итү.
Нәтиҗә ясау – Казан шәһәре–фән патшалыгы һәм мәдәни үзәк.
6. **Сочинение язарга әзерләнү. Темалар тәкъдим итү.**
Сөйләшүләрдән чыгып, укучылар, нәтиҗә ясый алабыз. Безнең башкалабызның тарихы бик бай. Казан - бик борынгы һәм шул ук вакытта яңа шәһәр. Башкалабызның үткәнен белергә, бүгенгесе белән горурланырга кирәк. Сезгә өч тема бирелә, әйдәгез планнар белән танышыйк.

**1 нче тема: Казан – Татарстанның башкаласы**.
/План дәреслекнең 148 нче битендә/
Дәреслек белән эшләү. Планны уку.

**2 нче тема: "Казан – борынгы шәһәр".**
План тактада язылган.
- Казан нинди елгалар буенда урнашкан?
- Казан исеме каян барлыкка килгән?
  - Риваятьләр ни сөйли?
- Тарихи һәм истәлекле урыннар. (рәсемнәр)
- Казанда музейлар һәм һәйкәлләр.

**3 нче тема: "Казан – мәдәният һәм белем үзәге."**
План интерактив тактада язылган.
- Казанда булган һәм яшәгән күренекле кешеләр.
- Казан университеты.
- Казанда югары уку йортлары.
- Казанда ял итү урыннары. /театрлар, китапханәләр, спорт сарае, күргәзмәләр.../

7. Укучылар план буенча сөйлиләр.

8. Планнарны дәфтәрләргә язу.
**"Казаным" җыры тыңланыла.**

9. Өйгә эш. Сочинение язарга.

10. Дәрескә нәтиҗә ясау. Билгеләр кую.